**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№61**
**14.01.2020**

Башкарма комитетның «Шәһәрнең күпфатирлы йортларындагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау фонды формалаштыру турында» 2014 елның 18 апрелендәге 2316 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

Күпфатирлы йорттагы торак милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фондын формалаштыру алымы үзгәртелү сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе мәгълүматы нигезендә, Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясы 7 бүлегенә туры китереп

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Шәһәрнең күпфатирлы йортларындагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау фонды формалаштыру турында» 2014 елның 18 апрелендәге 2316 номерлы карары кушымтасына (Башкарма комитетның 2017 елның 19 гыйнварындагы 181 номерлы, 2017 елның 1 июнендәге 3327 номерлы. 2017 елның 17 ноябрендәге 7049 номерлы, 2017 елның 5 декабрендәге 7542 номерлы, 2019 елның 14 маендагы 2468 номерлы карарлары редакциясендә) 1198, 1199 номерлы пунктларны төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев